РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ

422750, село Большая Атня,
улица Советская, дом 38

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422750, Олы Әтнә авылы,
Совет урамы,38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
13 сентябрь 2024ел.

**КАРАР**
№ 410

**«Җир кишәрлеген арендага, милеккә түләүгә торглар үткәрмичә генә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы Әтнә районы Башкарма комитетының 06.08.2021 ел, № 257 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

“Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып баруы турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында”гы 14.07.2022 ел, №312-ФЗ Федераль законына, “Табигый дәвалау ресурслары, дәвалау-савыктыру урыннары һәм курортлары турында” Федераль законга, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында” 04.08.2023 елның 469-ФЗ номерлы Федераль законына, “Россия Федерациясе Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында” 04.08.2023 № 492-ФЗ Федераль законына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында»28.02.2022 елның 175 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитеты карар бирә:

1. «Җир кишәрлеген арендага, милеккә түләүгә торглар үткәрмичә генә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы Әтнә районы Башкарма комитетының 06.08.2021 ел, № 257 карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. карарның преамбуласында “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары белән” сүзләрен “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ

регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында" 28.02.2022 № 175 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән" сүзләре белән алыштырырга;

1.2. административ регламентның 2.8.2.1 пунктының 6.2 пунктчасын түбәндәге эчтәлекле яңа абзац белән тулыландырырга:

"о) табигый дәвалау ресурсын санитария (тау-санитария) саклау округының беренче зонасы чикләрендә.";

1.3. Административ регламентның 2.8.2.1 пунктының 8-10 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә башка зат белән төзелгән йә аны комплекслы үстерү турында Карар кабул ителгән территория чикләрендә урнашкан, әгәр күрсәтелгән карарны гамәлгә ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәсә, җир кишәрлеген бирү турында гариза белән мондый җир кишәрлегендә урнашкан бина, корылма, андагы урыннар, тәмамланмаган төзелеш объекты милекчесе яисә мондый җир кишәрлегенең хокук иясе мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;

9) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә башка зат белән төзелгән йә аны комплекслы үстерү турында Карар кабул ителгән территория чикләрендә урнашкан, әгәр күрсәтелгән карарны гамәлгә ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәсә, яисә җир кишәрлеге территорияне комплекслы үстерү турында башка зат белән шартнамә төзелгән җир кишәрлегеннән төзелгән, мондый җир кишәрлеге федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны яисә җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән һәм мондый җир кишәрлеген бирү турында гариза белән күрсәтелгән объектларны төзүгә вәкаләтле зат мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;

10) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән җир кишәрлегеннән төзелгән йә, әгәр күрсәтелгән карарны гамәлгә ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәсә, аны комплекслы үстерү турында Карар кабул ителгән территория чикләрендә урнашкан, һәм территорияне планлаштыру буенча расланган документлар нигезендә федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны яисә җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән, җир кишәрлеген арендага бирү турында гариза белән территорияне комплекслы үстерү турында әлеге затның күрсәтелгән объектларны төзү буенча йөкләмәсен күздә тоткан шартнамә төзелгән зат мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;»;

1.4. административ регламентның 2.8.2.1 пунктының 13 нче пунктчасында "бакчачылык" сүзен "гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык алып баруы" сүзләренә алмаштырырга.;

1.5. регламентның 8 нче кушымтасының 23 пунктында "бу күчемсез милек объектлары бирелде" сүзләрен "Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге бминалар, корылмалар арендага бирелде" сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (https://atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Җитәкче А.Ф. Каюмов